**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Түбән Ләшәү авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2025 елның 26 ноябре** **№ 2**

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Түбән Ләшәү авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, өлкән, ялгыз яшәүче затлардан; Украина территориясендә хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
1) Түбән Ләшәү авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);
2) Түбән Ләшәү авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
3) Түбән Ләшәү авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);
4) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);

3. Әлеге карарны Ләшәү Тамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.З.Хабибуллин